| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.09.2023 п.г.т.Алексеевское № 327

**Алексеевск муниципаль районында**
**халыкның үлемен мониторинглау буенча**
**ведомствоара комиссия төзү турында**

Демографик хәл районның социаль-икътисади үсешен билгеләүче факторларның берсе булып тора. Үлемнәрне киметү һәм барлык кызыксынган учреждениеләрнең эшчәнлеген координацияләү максатыннан

**карар бирәм**:

1. Алексеевск муниципаль районында халыкның үлемен мониторинглау буенча ведомствоара комиссияне түбәндәге составта төзергә:

| | |
|---|---|
| Хәмзина Елена Александровна | -Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе |
| Вильданов Илнар Хәмитович | - «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССО ның баш табибы, комиссия рәисе урынбасары (килештерү буенча) |
| Сидорова Наталья Ивановна | - «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССО ның халыкка медицина хезмәте күрсәтү буенча баш табиб урынбасары, комиссия секретаре (килештерү буенча) |
| Бакеева Галина Валерьевна | - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге башлыгы |
| Хоснетдинов Рөстәм Рафикович | -Чистай, Спас, Алексеевск, Яңа Чишмә районнарында (Чистай ТО) кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә Роспотребнадзор территориаль идарәсенең Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (килештерү буенча) |
| Солдатова Марина Александровна | - Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге башлыгы (килештерү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ахмадаева Елена Дмитриевна | - «Заря», «Таң» газетасының баш мөхәррире (килештерү буенча) |
| Рыдаев Вячеслав Юрьевич | - «Алексеевск районында мәгариф бүлеге» МКУ җитәкчесе |
| Шакиров Руслан Илгизович | Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча ЮХИДИ җитәкчесе (килештерү буенча) |

2. Алексеевск муниципаль районында халыкның үлемен мониторинглау буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне расларга (Кушымта).

3. Башкарма комитетның 09.07.2009ел,№173 «Алексеевск муниципаль районында халыкның үлемен мониторинглау буенча ведомствоара комиссия төзү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е. А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **М. Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
18.09.2023ел, № 327
карарына кушымта

**Алексеевск муниципаль районында халыкның үлемен мониторинглау буенча ведомствоара комиссия турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләр

1.1. Алексеевск муниципаль районында халыкның үлемен мониторинглау буенча ведомствоара комиссия (алга таба - Комиссия) Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән төзелә.

1.2. Комиссияне Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары җитәкли.

1.3. Комиссия составына сәламәтлек саклау учреждениеләре, ЗАГС бүлеге, социаль яклау, мәгариф, Алексеевск муниципаль районы массакүләм мәгълүмат чаралары белгечләре һ. б. керә.

1.4. Комиссия карарлары Алексеевск муниципаль районының сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.

2. Бурычлар

Комиссиянең бурычлары булып тора:

2.1. Алексеевск муниципаль районында халыкның үлем сәбәпләрен анализлау.

2.2. Халыкның үлем дәрәҗәсен киметүгә, медицина ярдәменең сыйфатын яхшыртуга һәм оештыруга юнәлдерелгән ашыгыч һәм перспективалы идарәи карарларны эшләү һәм кабул итү.

2.3. Алексеевск муниципаль районында халык үлемен киметү стратегиясен эшләү.

3. Хокуклар һәм бурычлар

Комиссия хокуклы:

3.1. Комиссия эшенә кирәкле профильдәге белгечләрне, башка кызыксынучыларны кирәк булганда кертергә.

3.2. Алексеевск муниципаль районы медицина учреждениеләре тарафыннан үтәлергә тиешле карарлар чыгарырга.

3.3. Алексеевск муниципаль районы сәламәтлек саклау учреждениеләреннән Комиссия эше өчен кирәкле мәгълүматны (аналитик белешмәләр, медицина документларының төп нөсхәләре һ.б.) сорарга.

Комиссия бурычлы:

3.4. Халыкның үлем күрсәткечләрен, шул исәптән эшкә яраклы яшьтәгеләрнекен динамик анализлау.

3.5. Алексеевск муниципаль районы халкына медицина ярдәмен оештыру һәм сыйфатына анализ үткәрергә.

4. Комиссия эшен оештыру

4.1. Комиссия утырышлары кирәк булганда, әмма кварталга бер тапкырдан да сирәгрәк үткәрелми.

4.2. Комиссия утырышы анда төп составның 2/3 өлеше булганда хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия секретаре комиссия утырышы датасы билгеләнгәнче 7 көн алдан Комиссия рәисенә һәм аның урынбасарына каралган мәсьәләгә ярашлы рәвештә халыкның үлемен анализлауның статистик материалын тапшыра.

4.4. Комиссиянең чираттан тыш утырышы Комиссия әгъзасы тарафыннан Комиссия рәисенә нигезле тәкъдим белән инициативаланырга мөмкин.

4.5. Комиссиянең чираттан тыш утырышын үткәрү турында карарны Комиссия рәисе кабул итә.

4.6. Комиссия утырышлары төп состав белән дә, ачык утырышлар формасында да үткәрелергә мөмкин.

4.7. Комиссия утырышлары Башкарма комитетның административ бинасында да, Алексеевск муниципаль районының башка сәламәтлек саклау учреждениеләрендә(күчмә) дә үткәрелергә мөмкин.

4.8. Комиссия карарлары катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышлары белән кабул ителә.

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**